**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 13 апрелендәге 1202 номерлы карары**

**2026-2030 елларга Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту муниципаль программасы турында**

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, 1998 елның 24 июлендәге 125-ФЗ номерлы «Производстводагы бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү турында»гы федераль закон, 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында»гы федераль закон нигезендә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 10 ноябрендәге 799 номерлы «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында»гы карарын үтәү йөзеннән **карар бирәм**:

1. 2026-2030 елларга Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту муниципаль программасын (алга таба – Программа) әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

2. Казан шәһәре территориясендә урнашкан барлык милек формасындагы учреждениеләр, оешмалар һәм предприятиеләр җитәкчеләренә Программаны гамәлгә ашыру буенча чаралар күрергә тәкъдим итәргә.

3. Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка, Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасарлары А.И.Абзаловка, И.Ә.Гыйниятуллинга, И.С.Шакировка, И.В.Куляжевка, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе Б.Р.Алиевка, Казан шәһәре Башкарма комитетының районнар администрацияләре башлыклары Р.Х.Шәмсетдиновка, А.И.Салиховка, В.В.Жаворонковка, Р.Р.Фәтхетдиновка, Казан шәһәре Башкарма комитетының «Иске шәһәр» территориясе префекты А.Ш.Фәезовка ведомство карамагындагы бүлекчәләр, комитетлар, идарәләр тарафыннан Программаны гамәлгә ашыру буенча чаралар күрергә һәм хисап кварталыннан соң килә торган айның

15 нче числосына кадәр аны гамәлгә ашыру турында мәгълүматны Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитетына тапшыруны тәэмин итәргә.

4. 2026-2030 елларга Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә Программаны гамәлгә ашыру буенча чаралар планын расларга.

5. Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитетына (Г.Р.Минһаҗева):

5.1. Программаны үтәү буенча комитетлар, идарәләр, предприятиеләр эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итәргә;

5.2. ел саен, хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр, Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе Р.Г.Гафаровка Программаны үтәү йомгаклары турында мәгълүмат тапшыруны тәэмин итәргә;

5.3. ел саен, хисап елыннан соң килә торган елның 15 июленә кадәр, Программаны гамәлгә ашыру барышы һәм аның нәтиҗәлелеген бәяләү турында еллык хисап тапшырырга һәм Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе Р.Г.Гафаровка мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.

6. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 30 декабрендәге 3990 номерлы «2021-2025 елларга Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту программасы турында»гы карарын гамәлдән чыккан дип танырга.

7. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 13 апрелендәге
1202 номерлы карары белән
расланды

**2026-2030 елларга Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту муниципаль программасы**

**Программа паспорты**

| | |
|---|---|
| Программа атамасы | 2026-2030 елларга Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту муниципаль программасы |
| Программаны эшләү өчен нигезләр | Россия Федерациясе Хезмәт кодексы;<br>1998 елның 24 июлендәге 125-ФЗ номерлы «Производстводагы бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү турында»гы федераль закон;<br>1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында»гы федераль закон;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 10 ноябрендәге 799 номерлы «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында»гы карары;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 9 августындагы 553 номерлы «“Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү” Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында»гы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның |

| | |
|---|---|
| | 3 октябрендәге 1220 номерлы карары редакциясендә) |
| Программаның заказ бирүчесе | Казан шәһәре Башкарма комитеты |
| Программаны эшләүчеләр һәм башкаручылар | Эшләүчеләр – Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитеты, Казан шәһәрендә хезмәтне саклау буенча координация советы.<br>Башкаручылар – Казан шәһәре Башкарма комитетының тармак һәм территориаль органнары, Казан шәһәрендә хезмәтне саклау буенча координация советы, Казан шәһәрендә урнашкан барлык милек формасындагы оешмалар һәм учреждениеләр |
| Программаның максаты | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан оешмалар хезмәткәрләре өчен һөнәри авыруларга китерү ихтималы булган куркынычларны киметү максатыннан хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту |
| Программаның бурычлары | 1. Производствода бәхетсезлек очракларын һәм һөнәри авыруларны профилактикалау һәм кисәтү.<br>2. Хезмәтне саклау буенча уку-укыту һәм предприятиеләр/оешмалар җитәкчеләренең, белгечләренең хезмәтне саклау таләпләрен белүләрен тикшерү системасын камилләштерү.<br>3. Хезмәтне саклауны мәгълүмати яктан тәэмин итү һәм пропагандалау.<br>4. Хезмәт турындагы законнарның һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлешен тәэмин итүнең нәтиҗәлелеген арттыру |

| | |
|---|---|
| Программаны гамәлгә ашыру вакыты | 2026-2030 еллар |
| Программа белән билгеләнгән чараларны финанслау чыганаклары | Татарстан Республикасы бюджетыннан хезмәт шартларын яхшыртуга һәм хезмәтне саклауга юнәлдерелгән акчалар;<br>Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлекчәсе дәүләт учреждениесе акчалары;<br>Казан шәһәре оешмалары һәм предприятиеләре акчалары;<br>программа чараларын башкаручылар акчалары |
| Программаның мөһим максатчан индикаторлары һәм күрсәткечләре | Программа максатларына һәм бурычларына ирешү индикаторлары (күрсәткечләре):<br>- 1 мең эшләүчегә исәпләнгәндә, производствода бәхетсезлек килеп чыгу нәтиҗәсендә 1 эш көненә һәм аннан да күбрәк вакытка эшкә сәләтләрен югалткан һәм үлемгә китергән очраклардан зыян күрүчеләрнең саны;<br>- хезмәт шартлары зарарлы һәм (яки) куркыныч булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләр санының чагыштырма күләме (шәһәр икътисадында эшләүчеләрнең гомуми саныннан процентларда);<br>- 1 эш көненә һәм аннан да күбрәк вакытка эшкә сәләтләрен югалткан һәм үлемгә китергән очраклардан зыян күрүчеләрнең хезмәткә яраксыз булу көннәре саны |

## I. Барлыкка килү сәбәпләрен анализлауны кертеп, программаны гамәлгә ашыру юлы белән хәл ителә торган проблемага характеристика, аны Казан шәһәре муниципаль берәмлеге дәрәҗәсендә программа ысулы белән хәл итүнең максатка ярашлылыгы һәм зарурлыгы

Кеше сәламәтлеге социаль кыйммәтләр системасында төп урынны били һәм дәүләтнең иң мөһим ресурсы буларак карала. Һөнәри авырулар, имгәнүләр

дәүләткә зыян сала, һәм бу һөнәри авыруларга китерү ихтималы булган куркынычларны киметүгә, хезмәт шартларын яхшыртуга юнәлдерелгән нәтиҗәле чаралар күрүне таләп итә.

Икътисадтагы вазгыять, фәнни-техник прогресс, хезмәтне саклау белән идарә итү өлкәсендә тиешле закон актларында һәм норматив хокукый актларда билгеләнгән дәүләт сәясәте һәм әлеге актларны үтәү дәрәҗәсе хезмәт шартлары һәм хезмәтне саклау торышына йогынты ясаучы төп факторлар булып торалар.

Хезмәт ияләренең хезмәтне саклау турында Россия Федерациясе законнары, хезмәтне саклау, шул исәптән хезмәт гигиенасы һәм медицинасы буенча башка норматив хокукый актлар белән беркетелгән сәламәт һәм куркынычсыз хезмәт шартларына хокуклары тормышта һәрвакытта да тәэмин ителми, чөнки аларны гамәлгә ашыру механизмнары юк.

Производствода имгәнүләр, кешеләрнең һәлак булу проблемасы аеруча кискен тора. Производствода имгәнүләр дәрәҗәсе, ягъни бәхетсезлек очрагы килеп чыгу нәтиҗәсендә 1 эш көненә һәм аннан да күбрәк вакытка эшкә сәләтләрен югалткан һәм үлемгә китергән очраклардан зыян күрүчеләр саны, түбәндәге мәгълүматлар белән характерлана (1 таблица).

1 таблица

**Производствода имгәнүләр дәрәҗәсе (1 мең эшләүчегә исәпләгәндә) (Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы мәгълүматлары нигезендә)**

| **Татарстан Республикасы** | **2020 ел** | **2021 ел** | **2022 ел** | **2023 ел** | **2024 ел** |
|---|---|---|---|---|---|
| | 1,0 | 1,1 | 1,0 | 1,0 | 1,0 |
| шулардан үлем белән тәмамланган очраклар | 0,045 | 0,06 | 0,053 | 0,053 | 0,05 |
| **Казан шәһәре муниципаль берәмлеге** | 0,6 | 0,7 | 0,6 | 0,6 | 0,6 |
| шулардан үлем белән тәмамланган очраклар | 0,022 | 0,032 | 0,043 | 0,056 | 0,040 |

2024 елда Казан шәһәрендә производствода алынган имгәнүләр дәрәҗәсе 0,6 кеше тәшкил итте. Производствода үлемгә китергән имгәнүләр дәрәҗәсе – 0,040, бу республика буенча уртача күрсәткечтән 1,25 тапкыр түбән. Мондый күрсәткечләргә хезмәтне саклау өлкәсендәге проблемаларга игътибарны көчәйтү шартларында республика территориясендә барлык башкарма хакимият органнары эшен активлаштыру нәтиҗәсендә ирешелде. 2012 елдан башлап

хезмәтне саклау өлкәсендә Казан шәһәре Башкарма комитеты дәрәҗәсендә оештырылган эш шәһәрдәге оешмаларда имгәнү очракларын профилактикалауга һичшиксез үз өлешен кертте. Ул тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча шәһәр һәм территориаль комиссияләр эшчәнлеге кысаларында алып барыла.

Әмма шәһәрдә хезмәтне, хезмәт ияләренең гомерен һәм сәламәтлеген саклау өлкәсендәге вазгыять катлаулы булып кала. Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы мәгълүматлары буенча, 2024 елда Казан шәһәре предприятиеләрендә һәм оешмаларында производствода килеп чыккан бәхетсезлек очраклары нәтиҗәсендә 127 кеше зыян күргән, шуларның 8 е – үлгән.

2 таблица

**Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә производствода зыян күрүчеләр (Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы мәгълүматлары нигезендә)**

(кеше)

| | **2020 ел** | **2021 ел** | **2022 ел** | **2023 ел** | **2024 ел** |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 эш көненә һәм аннан да күбрәк вакытка эшкә сәләтләрен югалткан һәм үлемгә китергән очраклардан зыян күрүчеләр саны | 117 | 129 | 114 | 111 | 127 |
| шул исәптән хатын-кызлар | 34 | 45 | 47 | 32 | 42 |
| шулардан үлем белән тәмамланган очраклар | 4 | 6 | 8 | 11 | 8 |
| шул исәптән хатын-кызлар | - | - | - | - | 1 |
| 1 эш көненә һәм аннан да күбрәк вакытка эшкә сәләтләрен югалткан һәм үлемгә китергән очраклардан зыян күрүчеләрнең хезмәткә яраксыз булу көннәре саны | 6025 | 5829 | 5281 | 5923 | 6036 |

Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә производствода күпчелек бәхетсезлек очракларының килеп чыгу сәбәпләрен һәм шартларын анализлау шуны күрсәтә: алар беренче чиратта эшләр башкаруның канәгатьләнерлек дәрәҗәдә оештырылмавы белән бәйле.

Башка сәбәпләргә түбәндәгеләр керә:

- төзек булмаган машиналарны, механизмнарны һәм җайланмаларны эксплуатацияләү;

- хезмәтне саклау өлкәсендә куркынычсызлык кагыйдәләрен бозу;
- технологик процессларны үтәмәү һәм аларның камил булмавы;
- шәхси саклык чараларының булмавы;
- эш урыннарын канәгатьләнерлек дәрәҗәдә карап тотмау;
- эшләр башкаруны җитәкчеләр тарафыннан күзәтчелек итүнең җитәрлек дәрәҗәдә булмавы;
- хезмәтне саклау мәсьәләләре буенча уку-укытудагы җитешсезлекләр;
- хезмәткәрләрнең даими медицина тикшерүләре һәм диспансеризация узу практикасы булмау.

Хезмәт шартлары зарарлы һәм (яки) куркыныч булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләр санын анализлау түбәндәге нәтиҗәләрне ясарга мөмкинлек бирә: хезмәт шартлары зарарлы һәм (яки) куркыныч булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләр санының чагыштырма күләме 2020 елдан башлап 4 процентка кимеде һәм 2024 елда Казан шәһәрендә эшләүчеләрнең гомуми санынннан 31,3 процент тәшкил итте.

3 таблица

**Хезмәт шартлары зарарлы һәм (яки) куркыныч булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләр санының чагыштырма күләме (Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы мәгълүматлары нигезендә)**

| **Казан шәһәре муниципаль берәмлеге** | **2020 ел** | **2021 ел** | **2022 ел** | **2023 ел** | **2024 ел** |
|---|---|---|---|---|---|
| | 35,3 | 33,0 | 31,2 | 31,0 | 31,3 |

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 226 статьясы нигезендә хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау чараларын финанслау – эш бирүченең бурычы. Хезмәтне саклау чараларына тотылган чыгымнар предприятие җитәкчеләренең хезмәтне һәм үз хезмәткәрләренең гомерен һәм сәламәтлеген саклауга мөнәсәбәте, димәк, хезмәтне саклау белән идарә итүнең гамәлдәге системасының нәтиҗәлелеге индикаторы булып тора.

2024 елда Казан шәһәре предприятиеләрендә хезмәтне саклау чараларына 4373,2 млн сум акча тотылган. Бер эшләүчегә исәпләгәндә, хезмәтне саклау чараларына тотылган акчалар 21970,3 сум тәшкил иткән.

4 таблица

**Хезмәтне саклау чараларына тотылган чыгымнар (Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы мәгълүматлары нигезендә)**

| Хезмәтне саклау чараларына тотылган акчалар, млн сум | **2020 ел** | **2021 ел** | **2022 ел** | **2023 ел** | **2024 ел** |
|---|---|---|---|---|---|
| | 2448,3 | 2851,9 | 3429,7 | 4159,1 | 4373,2 |
| Бер эшләүчегә исәпләгәндә, хезмәтне саклау чараларына тотылган акчалар, сум | 13492,0 | 15171,5 | 18337,6 | 21274,7 | 21970,3 |

Хезмәткә яраклы халыкның тормыш сыйфатын күтәрү һәм сәламәтлеген саклау – программаны Казан шәһәре муниципаль берәмлеге дәрәҗәсендә эшләү һәм гамәлгә ашыру зарурлыгын билгеләүче мөһим факторлар.

Эшләүче халыкның хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау буенча чаралар күрү, һөнәри авыруга китерү ихтималы булган куркынычларны профилактикалау һәм киметү, шулай ук диспансеризация һәм профилактик тикшерүләр үткәрү халыкның сәламәтлеген саклау һәм үлем очракларын киметү буенча эшчәнлекнең өстенлекле юнәлешләре булып торалар.

## II. Программаның максаты һәм бурычлары

Программаның максаты – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан оешмалар хезмәткәрләре өчен һөнәри яктан килеп чыгу ихтималы булган куркынычларны киметү максатыннан хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту.

Куелган максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү мөһим:

- производствода бәхетсезлек очракларын һәм һөнәри авыруларны профилактикалау һәм кисәтү;
- уку-укытуның заманча технологияләре нигезендә хезмәтне саклау буенча хезмәткәрләрне өзлексез әзерләү;
- хезмәтне саклау мәсьәләләрен пропагандалау.

## III. Программаны гамәлгә ашырудан көтелә торган нәтиҗәләр һәм максатчан индикаторлар (күрсәткечләр)

Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә түбәндәгеләр көтелә:

- һөнәри авырулар һәм производствода алынган имгәнүләр дәрәҗәсен киметү;

- производствода бәхетсезлек очракларына һәм һөнәри авыруларга китерү ихтималы булган куркынычларны киметү;

- кисәтергә мөмкин булган сәбәпләр нәтиҗәсендә хезмәткә яраклы халык арасында килеп чыккан үлем очракларын киметү;

- производствода алынган гариплек яки һөнәри авыру нәтиҗәсендә инвалид калучылар санын киметү;

- Казан шәһәре территориясендә урнашкан оешмалар хезмәткәрләре өчен уңайлы хезмәт шартлары булдыру;

- авыр, зарарлы һәм куркыныч хезмәт шартларында эшләүче хезмәткәрләр санын киметү;

- хезмәткәрләрне зарарлы һәм куркыныч җитештерү факторларыннан саклау дәрәҗәсен арттыру;

- эшләүчеләрнең куркынычсызлыгын арттыру максатыннан эш бирүчеләр тарафыннан хезмәтне саклау чараларына бүлеп бирелә торган акчаларны арттыру;

- эш вакытын югалтуларны кыскарту хисабына хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру.

Программаның максатына ирешү һәм бурычларын хәл итү программа кушымтасында китерелгән максатчан индикаторлар (күрсәткечләр) белән бәяләнә.

Әлеге максатчан индикаторлар (күрсәткечләр) хезмәтне саклауның төп күрсәткечләреннән гыйбарәт, алар ел саен хезмәтне саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, Татарстан Республикасында Дәүләт хезмәт инспекциясе, Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлекчәсе дәүләт учреждениесе һәм Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы тарафыннан исәпләнә һәм тапшырыла.

Әлеге күрсәткечләрнең динамикасы башкарылган чараларның нәтиҗәлелеген күрсәтә.

## IV. Программа чараларының аларны гамәлгә ашыру вакыты һәм башкаручылар күрсәтелгән исемлеге

Программа чаралары системасы Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә хезмәт шартлары һәм хезмәтне саклау торышын һәрьяклап анализлау, статистик,

аналитик мәгълүмат һәм Казан шәһәрендә хезмәтне саклау буенча координация советы әгъзаларыннан кергән тәкъдимнәр нигезендә билгеләнә.

Программа белән түбәндәге төп юнәлешләр буенча килештерелгән гамәлләрне башкару күздә тотыла:

- Казан шәһәре предприятиеләрендә һәм оешмаларында хезмәтне саклау белән идарә итү системасын гамәлгә кертү;
- хезмәткәрләргә медицина-профилактика хезмәте күрсәтү системасын камилләштерү.

Программа бурычлары нигезендә төркемнәргә бүленгән программа чаралары исемлеге кушымтада китерелә.

Программа чараларын гамәлгә ашыру вакыты – 2026-2030 еллар.

## V. Программаның үзенчәлекләрен исәпкә алып, аны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү ысулы

Программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләрнең агымдагы зурлыкларын аларның максатчан зурлыклары белән чагыштыру юлы аша башкарыла. Шул ук вакытта программа чарасының нәтиҗәлелеге планлаштырылган максатлардан чыгып бәяләнә.

Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү аны гамәлгә ашыру вакыты дәвамында ел саен башкарыла.

Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеген юнәлешләр буенча бәяләү түбәндәге формула нигезендә башкарылган исәпләүләр буенча билгеләнә:

$$En = \frac{Tf1}{TN1} \times 100\%$$

, биредә:

En – программаның аерым юнәлешен гамәлгә ашыру барышының нәтиҗәлелеге (процентларда);

Tf1 – программаның аерым юнәлешен гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган, программаны гамәлгә ашыру барышында ирешелгән фактик индикатор;

TN1 – программа тарафыннан расланган норматив индикатор.

Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеген интеграль бәяләү түбәндәге формула нигезендә башкарылган исәпләүләр буенча билгеләнә:

$$E = \frac{\frac{Tf1}{TN1} + \frac{Tf2}{TN2} + \frac{Tf\text{n}}{TN\text{n}}}{M} \times 100\%$$

, биредә:

E – программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге (процентларда);

Tf – программаны гамәлгә ашыру барышында ирешелгән фактик индикаторлар;

TN – программа белән расланган норматив индикаторлар;

M – программа индикаторлары саны.

Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеген интеграль бәяләү күрсәткечен (E) исәпләү өчен программаның барлык максатчан индикаторлары кулланыла.

Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәлелегенең интеграль күрсәткече зурлыгы 80 проценттан 100 процентка кадәр булса, программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге – югары, 80 проценттан азрак булса, түбән дип таныла.

## VI. Программаны гамәлгә ашыру белән идарә итү механизмы

Программаны гамәлгә ашыру барышы заказ бирүче – программаның координаторы – Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан контрольдә тотыла. Ул программаны гамәлгә ашыру белән идарә итүне оештыру формаларын һәм ысулларын мөстәкыйль билгели.

Заказ бирүче – программаның координаторы:

- үз вәкаләтләре чикләрендә программаны гамәлгә ашыру өчен кирәкле норматив хокукый актлар эшли;
- программаны гамәлгә ашыру буенча хисап алып бара;
- программа чараларын гамәлгә ашыруның барышын контрольдә тота.

Заказ бирүче – программаның координаторы, кирәк булганда, программа чаралары буенча максатчан күрсәткечләрне, гамәлгә ашыру механизмын, шулай ук башкаручылар составын аныклый.

Заказ бирүче – программаның координаторы аны гамәлгә ашыру барышында:

- программаның нәтиҗәлелеген бәяләү максатыннан башкаручылар өчен хисап формаларын билгели;
- ел саен, хисап елыннан соң килә торган елның 1 маена кадәр, программаны башкаручылар белән берлектә программаны гамәлгә ашыру барышы һәм программаның нәтиҗәлелеген бәяләү турында еллык хисап әзерли;
- һәр ярты ел саен программаны башкаручылар тарафыннан программаның гамәлгә ашырылу барышын тикшерә;
- программаны гамәлгә ашыруның барышы һәм нәтиҗәләре турында мәгълүматны массакүләм мәгълүмат чараларында һәм электрон рәвештә урнаштыруны оештыра;

Документ создан в электронной форме. № 53977-Инф от 18.05.2026. Исполнитель: Переводчики
Страница 13 из 22. Страница создана: 18.05.2026 10:23
ЕМСЭД

- программа чараларын гамәлгә ашыру барышын яктырту мәсьәләләренә бәйле рәвештә массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек итә.

Программаны башкаручылар:

- һәр яртыеллыкта, хисап аеннан соң килә торган айның 15 нче числосыннан да соңга калмыйча, программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәләрен гомумиләштерәләр һәм анализлыйлар, заказ бирүчегә – программа координаторына хисаплар тапшыралар;

- ел саен, хисап елыннан соң килә торган елның 1 апреленә кадәр, программаны гамәлгә ашыру барышы һәм программа чараларының нәтиҗәлелеген бәяләү турында еллык хисап әзерлиләр һәм аны заказ бирүчегә – программа координаторына җибәрәләр;

- Программа чараларын гамәлгә ашыру өчен җавап бирәләр.

___________

2026-2030 елларга Казан шәһәре
муниципаль берәмлегендә
хезмәт шартларын һәм
хезмәтне саклауны яхшырту
муниципаль программасына
кушымта

**2026-2030 елларга Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту муниципаль программасын гамәлгә ашыру буенча чаралар планы**

| № т/б | Чараның атамасы | Башкару вакыты | Башкаручылар |
|---|---|---|---|
| **1** | **2** | **3** | **4** |
| Максатның атамасы: Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан оешмалар хезмәткәрләре өчен һөнәри авыруларга китерү ихтималы булган куркынычларны киметү максатыннан хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту | | | |
| 1. Бурычның атамасы: производствода бәхетсезлек очракларын һәм һөнәри авыруларны профилактикалау һәм кисәтү<br>**Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре –** 1 мең эшләүчегә исәпләнгәндә, производствода бәхетсезлек килеп чыгу нәтиҗәсендә 1 эш көненә һәм аннан да күбрәк вакытка эшкә сәләтләрен югалткан һәм үлемгә китергән очраклардан зыян күрүчеләр саны.<br>**Еллар буенча индикаторлар: 2026 – 0,6; 2027 – 0,58; 2028 – 0,56; 2029 – 0,52; 2030 – 0,5** | | | |
| 1.1 | Казан шәһәрендә хезмәтне саклау буенча координация советы эшен | 2026-2030 еллар | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитеты |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | тәэмин итү | | |
| 1.2 | Предприятиеләрдә һәм оешмаларда эшләүчеләрне шәхси саклык чаралары белән тәэмин итү | 2026-2030 еллар | Казан шәһәре оешмалары һәм предприятиеләре җитәкчеләре (килешү буенча), «Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм сәнәгатьчеләре ассоциациясе» эш бирүчеләрнең төбәк берләшмәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы профсоюзлары федерациясе (килешү буенча), Казан шәһәре Башкарма комитеты |
| 1.3 | Казан шәһәренең тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча территориаль комиссияләре утырышларында эш бирүчеләрнең производствода имгәнү очракларын һәм һөнәри авыруларны кисәтү, эш урыннарында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту буенча күрелә торган чаралар, бер төркем кеше катнашында килеп чыккан бәхетсезлек очракларының, үлемгә китергән бәхетсезлек очракларының сәбәпләре һәм аларны бетерү буенча күрелә торган чаралар турында чыгышларын тыңлау | 2026-2030 еллар | Казан шәһәре Башкарма комитетының районнар администрацияләре |
| 1.4 | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан оешмаларда бер төркем кеше катнашында килеп чыккан | 2026-2030 еллар | Казан шәһәре Башкарма комитетының районнар администрацияләре |

<table>
<tr><th>1</th><th>2</th><th>3</th><th>4</th></tr>
<tr><td></td><td>бәхетсезлек очракларын, үлемгә һәм авыр нәтиҗәләргә китергән бәхетсезлек очракларын тикшерүдә катнашу</td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>1.5</td><td>Милек формаларына бәйсез рәвештә Казан шәһәренең барлык оешмаларында, шул исәптән Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләрендә һәм ведомство карамагындагы муниципаль предприятиеләрдә һәм учреждениеләрдә, производствода имгәнү очракларын һәм һөнәри авыруларны киметүгә юнәлдерелгән хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту буенча чаралар планын эшләү һәм раслау</td><td>2026 елның 1 июленә кадәр</td><td>Казан шәһәре Башкарма комитеты, Казан шәһәренең муниципаль казна, автоном учреждениеләре һәм предприятиеләре, Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы профсоюзлары федерациясе (килешү буенча), «Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм сәнәгатьчеләре ассоциациясе» эш бирүчеләрнең төбәк берләшмәсе (килешү буенча)</td></tr>
<tr><td colspan="4">2. Бурычның атамасы: уку-укытуның заманча технологияләре нигезендә хезмәтне саклау буенча хезмәткәрләрне өзлексез әзерләү.<br>Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре – шәһәрдә хезмәт шартлары зарарлы һәм (яки) куркыныч булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләр санының чагыштырма күләме (шәһәр икътисадында эшләүчеләрнең гомуми санынннан процентларда)<br>Еллар буенча индикаторлар: 2026 – 30,8; 2027 – 30,5; 2028 – 30,2; 2029 – 30,0; 2030 – 29,5</td></tr>
<tr><td>2.1</td><td>Муниципаль бюджет, автоном учреждениеләрдә хезмәт шартларын махсус бәяләүне оештыру</td><td>2026-2027 еллар</td><td>Казан шәһәре Башкарма комитеты</td></tr>
<tr><td>2.2</td><td>Дәүләт статистикасы органнарына хезмәт шартларының һәм хезмәтне</td><td>2026-2030 еллар</td><td>Казан шәһәре оешмалары һәм предприятиеләре җитәкчеләре (килешү буенча),</td></tr>
</table>

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | саклауның торышы турында статистик хисап бирүне тәэмин итү | | Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәт инспекциясе (килешү буенча), «Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм сәнәгатьчеләре ассоциациясе» эш бирүчеләрнең төбәк берләшмәсе (килешү буенча) |
| 2.3 | Казан шәһәренең хезмәткәрләр саны 50 кешедән арткан оешмаларында һәм предприятиеләрендә Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 217 статьясы нигезендә хезмәтне саклау буенча хезмәт оештыру яки тиешле әзерлек узган яисә әлеге өлкәдә эш тәҗрибәсенә ия булган хезмәтне саклау буенча белгеч вазифасын булдыру | 2026-2030 еллар | Казан шәһәре оешмалары һәм предприятиеләре җитәкчеләре, Татарстан Республикасы профсоюзлары федерациясе (килешү буенча), Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәт инспекциясе (килешү буенча), Казан шәһәре Башкарма комитеты, Казан шәһәренең муниципаль казна, автоном учреждениеләре һәм предприятиеләре |
| 2.4 | Хезмәтне саклау мәсьәләләрен массакүләм мәгълүмат чараларында пропагандалау һәм яктырту | 2026-2030 еллар | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитеты, Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсе (килешү буенча), «Казан шәһәре иҗтимагый үзәге» муниципаль казна учреждениесе |
| 2.5 | Авыр эшләрдә һәм хезмәт шартлары зарарлы һәм (яки) куркыныч булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләр өчен беренчел һәм даими медицина тикшерүләре оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итү | 2026-2030 еллар | Казан шәһәре оешмалары һәм предприятиеләре җитәкчеләре, Татарстан Республикасы профсоюзлары федерациясе (килешү буенча) |
| 2.6 | Һөнәри һәм производство белән бәйле гомуми авыруларны башлангыч стадияләрендә үз вакытында ачыклау максатыннан | 2026-2030 еллар | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | хезмәт шартлары зарарлы һәм куркыныч булган производстволарда эшләүчеләр өчен беренчел һәм даими медицина тикшерүләре уздыру сыйфатын контрольдә тотуны гамәлгә ашыру. Мәҗбүри даими медицина тикшерүләрен үткәрү нәтиҗәсендә ачыкланган үтә көчле һәм хроник һөнәри авыруларның (агулануларның) беренчел һәм ахыргы диагнозы турында хәбәрнамәләрне теркәү һәм исәпкә алу | | (килешү буенча) |
| 2.7 | Казан шәһәренең сәнәгать предприятиеләрендә һәм оешмаларында хроник һәм үтә көчле һөнәри авырулар барлыкка килү сәбәпләрен һәм шартларын ачыклау буенча тикшерүләрдә катнашу | 2026-2030 еллар | Казан шәһәре предприятиеләре һәм оешмалары җитәкчеләре,<br>Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча),<br>Россия Федерациясе Социаль фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе (килешү буенча) |
| 3. Бурычның атамасы: хезмәтне саклау мәсьәләләрен пропагандалау.<br>**Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре –** 1 эш көненә һәм аннан да күбрәк вакытка эшкә сәләтләрен югалткан һәм үлемгә китергән очраклардан зыян күрүчеләрнең хезмәткә яраксыз булу көннәре саны.<br>**Еллар буенча индикаторлар: 2026 – 5800; 2027 – 5600; 2028 – 5300; 2029 – 5100; 2030 – 4900** | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 3.1 | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан предприятиеләрне һәм оешмаларны җәлеп итеп, куркынычсыз хезмәт шартларын тәэмин итү һәм производствода имгәнү очракларын киметү буенча семинарлар, киңәшмәләр, күргәзмәләр һәм башка оештыру-агарту чараларын оештыруда һәм уздыруда катнашу | 2026-2030 еллар | Казан шәһәре Башкарма комитеты, Татарстан Республикасы профсоюзлары федерациясе (килешү буенча), «Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм сәнәгатьчеләре ассоциациясе» эш бирүчеләрнең төбәк берләшмәсе (килешү буенча), Казан шәһәре оешмалары һәм предприятиеләре җитәкчеләре |
| 3.2 | Казан шәһәре предприятиеләрен һәм оешмаларын хезмәтне саклау өлкәсендә иң яхшы оештырылган эшкә багышланган смотр-конкурсларда катнашуга җәлеп итү | 2026-2030 еллар | «Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм сәнәгатьчеләре ассоциациясе» эш бирүчеләрнең төбәк берләшмәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы профсоюзлары федерациясе (килешү буенча), Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитеты, Казан шәһәре Башкарма комитетының районнар администрацияләре |
| 3.3 | Хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары мәсьәләләрендә уңай тәҗрибәне пропагандалауны оештыру | 2026-2030 еллар | Татарстан Республикасы профсоюзлары федерациясе (килешү буенча), «Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм сәнәгатьчеләре ассоциациясе» эш бирүчеләрнең төбәк берләшмәсе (килешү буенча), Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитеты,<br>Казан шәһәре Башкарма комитетының районнар администрацияләре |
| 3.4 | Халыкка Казан шәһәрендә хезмәт шартларының һәм хезмәтне | 2026-2030 еллар | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитеты, Татарстан Республикасы профсоюзлары |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | саклауның торышы турында мәгълүмат җиткерүне оештыру | | федерациясе (килешү буенча), «Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм сәнәгатьчеләре ассоциациясе» эш бирүчеләрнең төбәк берләшмәсе (килешү буенча) |
| 3.5 | Бөтендөнья хезмәтне саклау көнен, Бөтенроссия хезмәтне саклау атналыгын, хезмәтне саклау буенча белгечләрнең Бөтенроссия съездын үткәрү һәм хезмәтне саклау өлкәсендә алдынгы тәҗрибәне гамәлгә кертү кысаларында уздырыла торган чараларны мәгълүмати яктан тәэмин итү | 2026-2030 еллар | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитеты, Татарстан Республикасы профсоюзлары федерациясе (килешү буенча), «Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм сәнәгатьчеләре ассоциациясе» эш бирүчеләрнең төбәк берләшмәсе (килешү буенча) |
| 3.6 | Төзелеш һәм сәнәгать җитештерүенең эш мәйданчыкларын хезмәтне саклау һәм янгын куркынычсызлыгы буенча мәгълүмат белән тәэмин итүне оештыру (мәгълүмат стендлары, плакатлар) | 2026-2030 еллар | Казан шәһәре оешмалары һәм предприятиеләре җитәкчеләре, Татарстан Республикасы профсоюзлары федерациясе (килешү буенча) |
| 3.7 | Производствода имгәнүләрне һәм хезмәткәрләр арасында һөнәри авыруларны киметү буенча кисәтү чараларын, шулай ук  хезмәт шартлары зарарлы һәм (яки) куркыныч булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләрнең шифаханә-курортта дәвалануын финанслау мәсьәләләрен мәгълүмати яктан | 2026-2030 еллар | Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлекчәсе дәүләт учреждениесе (килешү буенча), Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитеты, Казан шәһәре Башкарма комитетының районнар администрацияләре |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | тәэмин итүне оештыру | | |
| 3.8 | Хезмәтне саклау турындагы законнарның эш бирүчеләр тарафыннан үтәлешен җәмәгать контролендә тотуны оештыру | 2026-2030 еллар | Татарстан Республикасы профсоюзлары федерациясе (килешү буенча) |
| 3.9 | Ел саен Казан шәһәренең сәнәгать предприятиеләре һәм оешмалары вәкилләре катнашында халыкның санитар-эпидемиологик иминлегенә кагылышлы актуаль мәсьәләләр буенча киңәшмәләр үткәрү | 2026-2030 еллар | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча), Казан шәһәре предприятиеләре һәм оешмалары җитәкчеләре |